**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменений в Закон Республики Татарстан «О введении на территории Республики Татарстан патентной системы налогообложения»**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
23 декабря 2020 года

**Статья 1**

Внести в Закон Республики Татарстан от 29 сентября 2012 года № 65-ЗРТ «О введении на территории Республики Татарстан патентной системы налогообложения» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2012, № 9; 2015, № 11 (I часть); 2016, № 5; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2020, № 1 (часть I); Официальный портал правовой информации Республики Татарстан (PRAVO.TATARSTAN.RU), 27 ноября 2020 года) изменения, изложив его в следующей редакции:

**«Закон Республики Татарстан**

**О введении на территории Республики Татарстан патентной системы налогообложения**

Статья 1. **Предмет регулирования настоящего Закона**

Настоящим Законом в соответствии с главой $26^5$ Налогового кодекса Российской Федерации на территории Республики Татарстан вводится в действие патентная система налогообложения.

Статья 2. **Виды предпринимательской деятельности, в отношении которых применяется патентная система налогообложения**

1. Патентная система налогообложения применяется в отношении следующих видов предпринимательской деятельности:

1) ремонт и пошив швейных, меховых и кожаных изделий, головных уборов и изделий из текстильной галантереи, ремонт, пошив и вязание трикотажных изделий по индивидуальному заказу населения;

2) ремонт, чистка, окраска и пошив обуви;

3) парикмахерские и косметические услуги;

4) стирка, химическая чистка и крашение текстильных и меховых изделий;

5) изготовление и ремонт металлической галантереи, ключей, номерных знаков, указателей улиц;

6) ремонт электронной бытовой техники, бытовых приборов, часов, металлоизделий бытового и хозяйственного назначения, предметов и изделий из металла, изготовление готовых металлических изделий хозяйственного назначения по индивидуальному заказу населения;

7) ремонт мебели и предметов домашнего обихода;

8) услуги в области фотографии;

9) ремонт, техническое обслуживание автотранспортных и мототранспортных средств, мотоциклов, машин и оборудования, мойка автотранспортных средств, полирование и предоставление аналогичных услуг;

10) оказание автотранспортных услуг по перевозке грузов автомобильным транспортом индивидуальными предпринимателями, имеющими на праве собственности или ином праве (пользования, владения и (или) распоряжения) транспортные средства, предназначенные для оказания таких услуг;

11) оказание автотранспортных услуг по перевозке пассажиров автомобильным транспортом индивидуальными предпринимателями, имеющими на праве собственности или ином праве (пользования, владения и (или) распоряжения) транспортные средства, предназначенные для оказания таких услуг;

12) реконструкция или ремонт существующих жилых и нежилых зданий, а также спортивных сооружений;

13) услуги по производству монтажных, электромонтажных, санитарно-технических и сварочных работ;

14) услуги по остеклению балконов и лоджий, нарезке стекла и зеркал, художественной обработке стекла;

15) услуги в сфере дошкольного образования и дополнительного образования детей и взрослых;

16) услуги по присмотру и уходу за детьми и больными;

17) сбор тары и пригодных для вторичного использования материалов;

18) деятельность ветеринарная;

19) сдача в аренду (наем) собственных или арендованных жилых помещений, а также сдача в аренду собственных или арендованных нежилых помещений (включая выставочные залы, складские помещения), земельных участков;

20) изготовление изделий народных художественных промыслов;

21) услуги по переработке продуктов сельского хозяйства, лесного хозяйства и рыболовства для приготовления продуктов питания для людей и корма для животных, а также производство различных продуктов промежуточного потребления, которые не являются пищевыми продуктами;

22) производство и реставрация ковров и ковровых изделий;

23) ремонт ювелирных изделий, бижутерии;

24) чеканка и гравировка ювелирных изделий;

25) деятельность в области звукозаписи и издания музыкальных произведений;

26) услуги по уборке квартир и частных домов, деятельность домашних хозяйств с наемными работниками;

27) деятельность, специализированная в области дизайна, услуги художественного оформления;

28) проведение занятий по физической культуре и спорту;

29) услуги носильщиков на железнодорожных вокзалах, автовокзалах, аэровокзалах, в аэропортах, морских, речных портах;

30) услуги платных туалетов;

31) услуги по приготовлению и поставке блюд для торжественных мероприятий или иных событий;

32) оказание услуг по перевозке пассажиров водным транспортом;

33) оказание услуг по перевозке грузов водным транспортом;

34) услуги, связанные со сбытом сельскохозяйственной продукции (хранение, сортировка, сушка, мойка, расфасовка, упаковка и транспортировка);

35) услуги, связанные с обслуживанием сельскохозяйственного производства (механизированные, агрохимические, мелиоративные, транспортные работы);

36) деятельность по благоустройству ландшафта;

37) охота, отлов и отстрел диких животных, в том числе предоставление услуг в этих областях, деятельность, связанная со спортивно-любительской охотой;

38) занятие медицинской деятельностью или фармацевтической деятельностью лицом, имеющим лицензию на указанные виды деятельности, за исключением реализации лекарственных препаратов, подлежащих обязательной маркировке средствами идентификации, в том числе контрольными (идентификационными) знаками в соответствии с Федеральным законом от 12 апреля 2010 года № 61-ФЗ «Об обращении лекарственных средств»;

39) осуществление частной детективной деятельности лицом, имеющим лицензию;

40) услуги по прокату;

41) услуги экскурсионные туристические;

42) организация обрядов (свадеб, юбилеев), в том числе музыкальное сопровождение;

43) организация похорон и предоставление связанных с ними услуг;

44) услуги уличных патрулей, охранников, сторожей и вахтеров;

45) розничная торговля, осуществляемая через объекты стационарной торговой сети, имеющие торговые залы;

46) розничная торговля, осуществляемая через объекты стационарной торговой сети, не имеющие торговых залов, а также через объекты нестационарной торговой сети;

47) услуги общественного питания, оказываемые через объекты организации общественного питания;

48) услуги общественного питания, оказываемые через объекты организации общественного питания, не имеющие зала обслуживания посетителей;

49) оказание услуг по забою и транспортировке скота;

50) производство кожи и изделий из кожи;

51) сбор и заготовка пищевых лесных ресурсов, недревесных лесных ресурсов и лекарственных растений;

52) переработка и консервирование фруктов и овощей;

53) производство молочной продукции;

54) растениеводство, услуги в области растениеводства;

55) производство хлебобулочных и мучных кондитерских изделий;

56) рыболовство и рыбоводство, рыболовство любительское и спортивное;

57) лесоводство и прочая лесохозяйственная деятельность;

58) деятельность по письменному и устному переводу;

59) деятельность по уходу за престарелыми и инвалидами;

60) сбор, обработка и утилизация отходов, а также обработка вторичного сырья;

61) резка, обработка и отделка камня для памятников;

62) разработка компьютерного программного обеспечения, в том числе системного программного обеспечения, приложений программного обеспечения, баз данных, web-страниц, включая их адаптацию и модификацию;

63) ремонт компьютеров и коммуникационного оборудования;

64) животноводство, услуги в области животноводства;

65) деятельность стоянок для транспортных средств;

66) помол зерна, производство муки и крупы из зерен пшеницы, ржи, овса, кукурузы или прочих хлебных злаков;

67) услуги по уходу за домашними животными;

68) изготовление и ремонт бондарной посуды и гончарных изделий по индивидуальному заказу населения;

69) услуги по изготовлению валяной обуви;

70) услуги по изготовлению сельскохозяйственного инвентаря из материала заказчика по индивидуальному заказу населения;

71) граверные работы по металлу, стеклу, фарфору, дереву, керамике, кроме ювелирных изделий по индивидуальному заказу населения;

72) изготовление и ремонт деревянных лодок по индивидуальному заказу населения;

73) ремонт игрушек и подобных им изделий;

74) ремонт спортивного и туристического оборудования;

75) услуги по вспашке огородов по индивидуальному заказу населения;

76) услуги по распиловке дров по индивидуальному заказу населения;

77) сборка и ремонт очков;

78) изготовление и печатание визитных карточек и пригласительных билетов на семейные торжества;

79) переплетные, брошюровочные, окантовочные, картонажные работы;

80) услуги по ремонту сифонов и автосифонов, в том числе зарядка газовых баллончиков для сифонов;

81) изготовление ювелирных изделий и аналогичных изделий по индивидуальному заказу населения;

82) изготовление бижутерии и подобных товаров по индивидуальному заказу населения.

2. Патентная система налогообложения не применяется в отношении видов деятельности, установленных пунктом 6 статьи $346^{43}$ Налогового кодекса Российской Федерации.

Статья 3. **Территории действия патентов по группам муниципальных образований**

Дифференцировать территорию Республики Татарстан по территориям действия патентов, за исключением патентов на осуществление видов предпринимательской деятельности, указанных в пунктах 10, 11, 32, 33, 46 (в части, касающейся развозной и разносной розничной торговли) части 1 статьи 2 настоящего Закона, по следующим группам муниципальных образований:

1) 1 группа – муниципальное образование город Казань;

2) 2 группа – муниципальное образование «город Набережные Челны», Альметьевский, Нижнекамский муниципальные районы;

3) 3 группа – Азнакаевский, Бавлинский, Бугульминский, Елабужский, Заинский, Зеленодольский, Лаишевский, Лениногорский, Нурлатский, Тукаевский муниципальные районы;

4) 4 группа – Агрызский, Актанышский, Арский, Буинский, Высокогорский, Менделеевский, Новошешминский, Пестречинский, Сабинский, Сармановский, Чистопольский, Ютазинский муниципальные районы;

5) 5 группа – Аксубаевский, Алексеевский, Алькеевский, Апастовский, Атнинский, Балтасинский, Верхнеуслонский, Дрожжановский, Кайбицкий, Камско-Устьинский, Кукморский, Мамадышский, Мензелинский, Муслюмовский, Рыбно-Слободский, Спасский, Тетюшский, Тюлячинский, Черемшанский муниципальные районы.

Статья 4. **Размеры потенциально возможного к получению индивидуальным предпринимателем годового дохода по видам предпринимательской деятельности, в отношении которых применяется патентная система налогообложения**

1. Установить следующие размеры потенциально возможного к получению индивидуальным предпринимателем годового дохода по видам предпринимательской деятельности, осуществляемым на территории Республики Татарстан, в отношении которых применяется патентная система налогообложения:

1) для видов предпринимательской деятельности, предусмотренных пунктами 1 – 8, 12 – 18, 20 – 31, 34 – 44, 49 – 64, 66 – 82 части 1 статьи 2 настоящего Закона, осуществляемых без привлечения наемных работников, – 1 000,0 тыс. рублей, дополнительно при привлечении наемных работников на одну единицу средней численности наемных работников, – 300,0 тыс. рублей;

2) для вида предпринимательской деятельности, предусмотренного пунктом 9 части 1 статьи 2 настоящего Закона, осуществляемого без привлечения наемных работников, – 1 400,0 тыс. рублей, дополнительно при привлечении наемных работников на одну единицу средней численности наемных работников, – 450,0 тыс. рублей;

3) для вида предпринимательской деятельности, предусмотренного пунктом 10 части 1 статьи 2 настоящего Закона, – 450,0 тыс. рублей на единицу автотранспортного средства;

4) для вида предпринимательской деятельности, предусмотренного пунктом 11 части 1 статьи 2 настоящего Закона, на единицу автотранспортного средства:

а) для оказания автотранспортных услуг по перевозке пассажиров автомобильным транспортом в части деятельности легкового такси – 350,0 тыс. рублей;

б) для оказания автотранспортных услуг по перевозке пассажиров автомобильным транспортом, за исключением деятельности легкового такси, – 1 200,0 тыс. рублей;

5) для вида предпринимательской деятельности, предусмотренного пунктом 19 части 1 статьи 2 настоящего Закона, на один квадратный метр площади сдаваемого в аренду (наем) собственного или арендованного жилого помещения и (или) нежилого помещения (включая выставочные залы, складские помещения), земельного участка:

а) 12,0 тыс. рублей – для 1 группы муниципальных образований;

б) 10,8 тыс. рублей – для 2 группы муниципальных образований;

в) 9,6 тыс. рублей – для 3 группы муниципальных образований;

г) 8,4 тыс. рублей – для 4 группы муниципальных образований;

д) 7,2 тыс. рублей – для 5 группы муниципальных образований;

6) для вида предпринимательской деятельности, предусмотренного пунктом 32 части 1 статьи 2 настоящего Закона, – 1 000,0 тыс. рублей на единицу судов водного транспорта;

7) для вида предпринимательской деятельности, предусмотренного пунктом 33 части 1 статьи 2 настоящего Закона, – 500,0 тыс. рублей на единицу судов водного транспорта;

8) для вида предпринимательской деятельности, предусмотренного пунктом 45 части 1 статьи 2 настоящего Закона, при площади торгового зала до 10 квадратных метров (включительно) – 866,2 тыс. рублей на один объект стационарной торговой сети, при площади торгового зала более 10 квадратных метров – 86,6 тыс. рублей на один квадратный метр площади объекта стационарной торговой сети;

9) для вида предпринимательской деятельности, предусмотренного пунктом 46 части 1 статьи 2 настоящего Закона:

а) для розничной торговли, осуществляемой через объекты стационарной торговой сети, не имеющие торговых залов, за исключением розничной торговли с использованием торговых автоматов, при площади объекта стационарной торговой сети, не имеющего торгового зала, до 10 квадратных метров (включительно) – 866,2 тыс. рублей на один объект стационарной торговой сети, при площади объекта

стационарной торговой сети более 10 квадратных метров – 86,6 тыс. рублей на один квадратный метр площади объекта стационарной торговой сети;

б) для розничной торговли, осуществляемой через объекты стационарной торговой сети, не имеющие торговых залов, с использованием торговых автоматов, – 270,7 тыс. рублей на один торговый автомат;

в) для розничной торговли, осуществляемой через объекты нестационарной торговой сети, в том числе в части развозной и разносной розничной торговли, – 812,0 тыс. рублей на один объект нестационарной торговой сети;

10) для вида предпринимательской деятельности, предусмотренного пунктом 47 части 1 статьи 2 настоящего Закона, при площади зала обслуживания до 10 квадратных метров (включительно) – 481,0 тыс. рублей на один объект организации общественного питания, при площади зала обслуживания более 10 квадратных метров – 48,1 тыс. рублей на один квадратный метр площади объекта организации общественного питания;

11) для вида предпринимательской деятельности, предусмотренного пунктом 48 части 1 статьи 2 настоящего Закона, – 812,0 тыс. рублей на один объект организации общественного питания;

12) для вида предпринимательской деятельности, предусмотренного пунктом 65 части 1 статьи 2 настоящего Закона, – 3,0 тыс. рублей на один квадратный метр площади стоянки для транспортных средств.

2. Установить, что к размеру потенциально возможного к получению индивидуальным предпринимателем годового дохода, установленному частью 1 настоящей статьи по видам предпринимательской деятельности, предусмотренным пунктами 1 – 9, 12 – 18, 20 – 31, 34 – 46 (за исключением предпринимательской деятельности, касающейся развозной и разносной розничной торговли), 47 – 82 части 1 статьи 2 настоящего Закона, в зависимости от территории действия патентов по группам муниципальных образований, установленным статьей 3 настоящего Закона, применяется коэффициент, равный:

1) 1,0 – для 1 группы муниципальных образований;
2) 0,95 – для 2 группы муниципальных образований;
3) 0,89 – для 3 группы муниципальных образований;
4) 0,83 – для 4 группы муниципальных образований;
5) 0,78 – для 5 группы муниципальных образований.».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу по истечении одного месяца со дня его официального опубликования, но не ранее 1-го числа очередного налогового периода по налогу, уплачиваемому в связи с применением патентной системы налогообложения.

ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Президент
Республики Татарстан | Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
25 декабря 2020 года
№ 90-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» 2012 елның 29 сентябрендәге 65-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 9; 2015, № 11 (I өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2020, № 1 (I өлеш); Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы (PRAVO.TATARSTAN.RU), 2020 елның 27 ноябре), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

**«Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында**

**Татарстан Республикасы Законы**

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон белән Россия Федерациясе Салым кодексының $26^5$ бүлеге нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасы гамәлгә кертелә.

2 статья. **Салым салуның патент системасы кулланыла торган эшкуарлык эшчәнлегенең төрләре**

1. Салым салуның патент системасы эшкуарлык эшчәнлегенең түбәндәге төрләренә карата кулланыла:

1) тукыма, мех һәм күн әйберләр, баш киемнәре, текстиль галантереясы әйберләре ремонтлау һәм тегү, халыкның индивидуаль заказы буенча трикотаж әйберләр ремонтлау, тегү һәм бәйләү;

2) аяк киемнәре ремонтлау, чистарту, буяу һәм тегү;

3) чәчтарашханә хезмәтләре һәм косметик хезмәтләр күрсәтү;

4) текстиль һәм мех әйберләрне юу, химик чистарту һәм буяу;

5) металл галантереясы әйберләре, ачкычлар, номер билгеләре, урам күрсәткечләре ясау һәм ремонтлау;

6) электрон көнкүреш техникасы, көнкүреш приборлары, сәгатьләр, көнкүреш һәм хуҗалык билгеләнешендәге металл әйберләр, металл предметлар һәм әйберләр ремонтлау, халыкның индивидуаль заказы буенча хуҗалык билгеләнешендәге әзер металл әйберләр ясау;

7) җиһаз һәм көнкүреш кирәк-яраклары ремонтлау;

8) фотография өлкәсендә хезмәтләр күрсәтү;

9) автотранспорт һәм мототранспорт чаралары, мотоцикллар, машиналар һәм җайланмалар ремонтлау, аларга техник хезмәт күрсәтү, автотранспорт чаралары юу, аларны полировкалау һәм башка шундый хезмәтләр күрсәтү;

10) милек хокукында яисә башка хокукта (файдалану, биләү һәм (яки) эш итү) автомобиль транспорты белән йөк ташу буенча автотранспорт хезмәтләре күрсәтү өчен билгеләнгән транспорт чаралары булган индивидуаль эшкуарлар тарафыннан мондый хезмәтләр күрсәтү;

11) милек хокукында яисә башка хокукта (файдалану, биләү һәм (яки) эш итү) автомобиль транспорты белән пассажирлар ташу буенча автотранспорт хезмәтләре күрсәтү өчен билгеләнгән транспорт чаралары булган индивидуаль эшкуарлар тарафыннан мондый хезмәтләр күрсәтү;

12) гамәлдәге торак һәм торак булмаган биналар, шулай ук спорт корылмалары реконструкцияләү яки ремонтлау;

13) монтаж, электромонтаж, санитар-техник һәм эретеп ябыштыру эшләре башкару буенча хезмәтләр күрсәтү;

14) балконнарга һәм лоджияләргә пыяла кую, пыяла һәм көзгеләр кисү, пыяланы сәнгатьчә эшкәртү хезмәтләре күрсәтү;

15) мәктәпкәчә белем бирү, балаларга һәм өлкәннәргә өстәмә белем бирү өлкәсендә хезмәтләр күрсәтү;

16) балаларны һәм авыруларны карау һәм тәрбияләү хезмәтләре күрсәтү;

17) савытлар һәм кабат куллану өчен яраклы материаллар җыю;

18) ветеринария эшчәнлеге;

19) шәхси яисә арендага алынган торак урыннарны арендага (наемга) бирү, шулай ук шәхси яки арендага алынган торак булмаган урыннарны (күргәзмә залларын, склад бүлмәләрен кертеп), җир кишәрлекләрен арендага бирү;

20) халык сәнгать кәсепләре әйберләре ясау;

21) кешеләр өчен туклану продуктлары һәм хайваннар өчен азык әзерләү буенча авыл хуҗалыгы, урман хуҗалыгы һәм балыкчылык продуктларын эшкәртү хезмәтләре күрсәтү, шулай ук азык-төлек продуктлары булмаган төрле арадаш куллану продуктлары җитештерү;

22) келәмнәр һәм келәм әйберләр җитештерү һәм реставрацияләү;

23) зәркән әйберләр, бижутерия ремонтлау;

24) зәркән әйберләр кою һәм аларны уеп бизәкләү;

25) тавыш яздыру һәм музыкаль әсәрләр бастырып чыгару өлкәсендә эшчәнлек;

26) фатирлар һәм шәхси йортлар җыештыру буенча хезмәтләр күрсәтү, ялланган хезмәткәрләр белән йорт хуҗалыгы эшчәнлеге;

27) дизайн өлкәсендә махсуслаштырылган эшчәнлек, сәнгатьчә бизәү хезмәтләре күрсәтү;

28) физик культура һәм спорт буенча дәресләр үткәрү;

29) тимер юл вокзалларында, автовокзалларда, аэровокзалларда, аэропортларда, диңгез һәм елга портларында йөк ташучы хезмәтләре күрсәтү;

30) түләүле бәдрәф хезмәтләре күрсәтү;

31) тантаналы чаралар яисә башка чаралар өчен ризык әзерләү һәм китереп тапшыру буенча хезмәтләр күрсәтү;

32) су транспортында пассажирлар йөртү буенча хезмәтләр күрсәтү;

33) су транспортында йөк ташу буенча хезмәтләр күрсәтү;

34) авыл хуҗалыгы продукциясен сату белән бәйле хезмәтләр күрсәтү (саклау, аралау, киптерү, юу, тутыру, төргәкләү һәм транспортировкалау);

35) авыл хуҗалыгы җитештерүенә хезмәт күрсәтүгә бәйле хезмәтләр күрсәтү (механикалаштырылган, агрохимик, мелиоратив, транспорт эшләре);

36) ландшафт төзекләндерү буенча эшчәнлек;

37) кыргый хайваннар аулау, тоту һәм ату, шул исәптән бу өлкәләрдә хезмәтләр күрсәтү, спорт-һәвәскәр аучылык белән бәйле эшчәнлек;

38) медицина яисә фармацевтика эшчәнлегенә лицензиясе булган зат тарафыннан эшчәнлекнең күрсәтелгән төрләре белән шөгыльләнү, идентификацияләү чаралары, шул исәптән «Дарулар әйләнеше турында» 2010 елның 12 апрелендәге 61-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә контроль (идентификация) билгеләре белән мәҗбүри маркировкаланырга тиешле дару препаратлары сатудан тыш;

39) лицензиясе булган зат тарафыннан шәхси детектив эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

40) прокатка бирү буенча хезмәтләр күрсәтү;

41) туристлык экскурсиясе хезмәтләре күрсәтү;

42) йолалар оештыру (туйлар, юбилейлар), шул исәптән музыка белән тәэмин итү;

43) җирләү эшләрен оештыру һәм аларга бәйле хезмәтләр күрсәтү;

44) урам патрульләре, сакчылар, каравылчылар һәм вахтерлар хезмәтләре күрсәтү;

45) сәүдә заллары булган стационар сәүдә челтәре объектлары аша гамәлгә ашырыла торган ваклап сату;

46) сәүдә заллары булмаган стационар сәүдә челтәре объектлары аша, шулай ук стационар булмаган сәүдә челтәре объектлары аша гамәлгә ашырыла торган ваклап сату;

47) җәмәгать туклануын оештыру объектлары аша күрсәтелә торган җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтү;

48) кулланучыларга хезмәт күрсәтү залы булмаган җәмәгать туклануын оештыру объектлары аша күрсәтелә торган җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтү;

49) терлек суюю һәм транспортировкалау буенча хезмәтләр күрсәтү;

50) күн һәм күннән әйберләр җитештерү;

51) ашарга яраклы урман ресурсларын, агач булмаган урман ресурсларын һәм дару үләннәрен җыю һәм әзерләү;

52) җиләк-җимеш һәм яшелчәләр эшкәртү һәм консервлау;

53) сөт продукциясе җитештерү;

54) үсемлекчелек, үсемлекчелек өлкәсендә хезмәтләр күрсәтү;

55) ипи-күмәч һәм камыр кондитер әйберләре җитештерү;

56) балыкчылык һәм балык үрчетү, һәвәскәр һәм спорт балыкчылыгы;

57) урманчылык эше һәм башка урман хуҗалыгы эшчәнлеге;

58) язма һәм телдән тәрҗемә эшчәнлеге;

59) өлкәннәрне һәм инвалидларны карау эшчәнлеге;

60) калдыкларны җыю, эшкәртү һәм утильләштерү, шулай ук кулланылышта булган чималны эшкәртү;

61) һәйкәлләр өчен таш кисү, эшкәртү һәм бизәү;

62) компьютер программаларын, шул исәптән система программаларын, программа өчен кушымталар, белешмәләр базалары, web-битләр эшләү, аларны яраклаштыруны һәм яңартуны да кертеп;

63) компьютерлар һәм коммуникация җайланмалары ремонтлау;

64) терлекчелек, терлекчелек өлкәсендә хезмәтләр күрсәтү;

65) транспорт чараларын куеп тору урыннары эшчәнлеге;

66) он тарттыру, бодай, арыш, солы, кукуруз һәм башка бөртеклеләрдән он һәм ярмалар җитештерү;

67) йорт хайваннарын карау буенча хезмәтләр күрсәтү;

68) халыкның индивидуаль заказы буенча агач савыт-саба һәм балчык әйберләр ясау һәм ремонтлау;

69) киез аяк киеме ясау буенча хезмәтләр күрсәтү;

70) халыкның индивидуаль заказы буенча заказчы материалыннан авыл хуҗалыгы коралы әзерләү буенча хезмәтләр күрсәтү;

71) металлга, пыялага, фарфорга, агачка, керамикага уеп бизәкләр төшерү эшләре, халыкның индивидуаль заказы буенча зәркән әйберләрдән тыш;

72) халыкның индивидуаль заказы буенча агач көймәләр ясау һәм ремонтлау;

73) уенчыклар һәм аларга охшаш әйберләр ремонтлау;

74) спорт һәм туристлык җиһазларын ремонтлау;

75) халыкның индивидуаль заказы буенча бакчалар сөрү хезмәтләре күрсәтү;

76) халыкның индивидуаль заказы буенча утын кисү хезмәтләре күрсәтү;

77) күзлекләр ясау һәм ремонтлау;

78) визит карточкалары һәм гаилә тантаналарына чакыру билетлары әзерләү һәм бастырып чыгару;

79) төпләү, брошюралау, каймалау, картон эшләре;

80) сифоннар һәм автосифоннар ремонтлау хезмәтләре күрсәтү, шул исәптән сифоннар өчен газ баллончыкларын тутыру;

81) халыкның индивидуаль заказы буенча зәркән әйберләр һәм аларга охшаш әйберләр ясау;

82) халыкның индивидуаль заказы буенча бижутерия һәм шундый ук товарлар ясау.

2. Салым салуның патент системасы Россия Федерациясе Салым кодексының $346^{43}$ статьясындагы 6 пунктында билгеләнгән эшчәнлек төрләренә карата кулланылмый.

**3 статья. Муниципаль берәмлекләр төркемнәре буенча патентларның гамәлдә булу территорияләре**

Әлеге Законның 2 статьясындагы 1 өлешенең 10, 11, 32, 33, 46 (транспорт белән һәм җәяү таратыла торган ваклап сату өлешендә) пунктларында күрсәтелгән эшкуарлык эшчәнлеге төрләрен гамәлгә ашыруга патентлардан тыш, патентларның гамәлдә булу территорияләре буенча Татарстан Республикасы территориясен муниципаль берәмлекләрнең түбәндәге төркемнәре буенча дифференциацияләргә:

1) 1 нче төркем – Казан шәһәре муниципаль берәмлеге;

2) 2 нче төркем – «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге, Әлмәт, Түбән Кама муниципаль районнары;

3) 3 нче төркем – Азнакай, Баулы, Бөгелмә, Алабуга, Зәй, Зеленодольск, Лаеш, Лениногорск, Нурлат, Тукай муниципаль районнары;

4) 4 нче төркем – Әгерҗе, Актаныш, Арча, Буа, Биектау, Менделеевск, Яңа Чишмә, Питрәч, Саба, Сарман, Чистай, Ютазы муниципаль районнары;

5) 5 нче төркем – Аксубай, Алексеевск, Әлки, Апас, Әтнә, Балтач, Югары Ослан, Чүпрәле, Кайбыч, Кама Тамагы, Кукмара, Мамадыш, Минзәлә, Мөслим, Балык Бистәсе, Спас, Тәтеш, Теләче, Чирмешән муниципаль районнары.

4 статья. **Салым салуның патент системасы кулланыла торган эшкуарлык эшчәнлеге төрләре буенча индивидуаль эшкуар потенциаль алырга мөмкин булган еллык керемнең күләмнәре**

1. Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашырылучы эшкуарлык эшчәнлегенең салым салуның патент системасы кулланыла торган төрләре буенча индивидуаль эшкуар потенциаль алырга мөмкин булган еллык керемнең түбәндәге күләмнәрен билгеләргә:

1) әлеге Законның 2 статьясындагы 1 өлешенең 1 – 8, 12 – 18, 20 – 31, 34 – 44, 49 – 64, 66 – 82 пунктларында каралган, ялланып эшләүчеләрне җәлеп итмичә гамәлгә ашырыла торган эшкуарлык эшчәнлеге төрләре өчен – 1 000,0 мең сум, ялланып эшләүчеләрне аларның уртача саныннан бер берәмлеккә җәлеп иткәндә, өстәмә рәвештә – 300,0 мең сум;

2) әлеге Законның 2 статьясындагы 1 өлешенең 9 пунктында каралган, ялланып эшләүчеләрне җәлеп итмичә гамәлгә ашырыла торган эшкуарлык эшчәнлеге төре

өчен – 1 400,0 мең сум, ялланып эшләүчеләрне аларның уртача санынннан бер берәмлеккә җәлеп иткәндә, өстәмә рәвештә – 450,0 мең сум;

3) әлеге Законның 2 статьясындагы 1 өлешенең 10 пунктында каралган эшкуарлык эшчәнлеге төре өчен – бер берәмлек автотранспорт чарасына 450,0 мең сум;

4) әлеге Законның 2 статьясындагы 1 өлешенең 11 пунктында каралган эшкуарлык эшчәнлеге төре өчен, бер берәмлек автотранспорт чарасына:

а) автомобиль транспортында пассажирлар ташу буенча автотранспорт хезмәтләре күрсәткән өчен, җиңел такси эшчәнлеге өлешендә, – 350,0 мең сум;

б) автомобиль транспортында пассажирлар ташу буенча автотранспорт хезмәтләре күрсәтү өчен, җиңел такси эшчәнлегеннән тыш, – 1 200,0 мең сум;

5) әлеге Законның 2 статьясындагы 1 өлешенең 19 пунктында каралган эшкуарлык эшчәнлеге төре өчен, арендага (наемга) тапшырыла торган шәхси яки арендага алынган торак урын һәм (яисә) торак булмаган урын (күргәзмә залларын, склад бүлмәләрен дә кертеп), җир кишәрлеге мәйданының бер квадрат метрына:

а) 12,0 мең сум – муниципаль берәмлекләрнең 1 нче төркеме өчен;

б) 10,8 мең сум – муниципаль берәмлекләрнең 2 нче төркеме өчен;

в) 9,6 мең сум – муниципаль берәмлекләрнең 3 нче төркеме өчен;

г) 8,4 мең сум – муниципаль берәмлекләрнең 4 нче төркеме өчен;

д) 7,2 мең сум – муниципаль берәмлекләрнең 5 нче төркеме өчен;

6) әлеге Законның 2 статьясындагы 1 өлешенең 32 пунктында каралган эшкуарлык эшчәнлеге төре өчен – су транспорты судноларының бер берәмлегенә 1 000,0 мең сум;

7) әлеге Законның 2 статьясындагы 1 өлешенең 33 пунктында каралган эшкуарлык эшчәнлеге төре өчен – су транспорты судноларының бер берәмлегенә 500,0 мең сум;

8) әлеге Законның 2 статьясындагы 1 өлешенең 45 пунктында каралган эшкуарлык эшчәнлеге төре өчен, сәүдә залының мәйданы 10 квадрат метрга кадәр (аны кертеп) булганда – стационар сәүдә челтәренең бер объектына 866,2 мең сум, сәүдә залының мәйданы 10 квадрат метрдан артык булганда – стационар сәүдә челтәре объекты мәйданының бер квадрат метрына 86,6 мең сум;

9) әлеге Законның 2 статьясындагы 1 өлешенең 46 пунктында каралган эшкуарлык эшчәнлеге төре өчен:

а) сәүдә залы булмаган стационар сәүдә челтәре объектлары аша гамәлгә ашырыла торган ваклап сату өчен, сәүдә автоматларыннан файдаланып гамәлгә ашырыла торган ваклап сатудан тыш, сәүдә залы булмаган стационар сәүдә челтәре объектының мәйданы 10 квадрат метрга кадәр (аны кертеп) булганда – стационар сәүдә челтәренең бер объектына 866,2 мең сум, стационар сәүдә челтәре объектының мәйданы 10 квадрат метрдан артып киткән очракта – стационар сәүдә челтәре объекты мәйданының бер квадрат метрына 86,6 мең сум;

б) сәүдә заллары булмаган стационар сәүдә челтәре объектлары аша сәүдә автоматларыннан файдаланып башкарыла торган ваклап сату өчен – бер сәүдә автоматына 270,7 мең сум;

в) стационар булмаган сәүдә челтәре объектлары аша гамәлгә ашырыла торган ваклап сату өчен, шул исәптән транспорт белән һәм җәяү таратыла торган ваклап сату өлешендә, – стационар булмаган сәүдә челтәренең бер объектына 812,0 мең сум;

10) әлеге Законның 2 статьясындагы 1 өлешенең 47 пунктында каралган эшкуарлык эшчәнлеге төре өчен, хезмәт күрсәтү залының мәйданы 10 квадрат метрга кадәр (аны кертеп) булганда – җәмәгать туклануын оештыруның бер объектына 481,0 мең сум, хезмәт күрсәтү залының мәйданы 10 квадрат метрдан артык булганда – җәмәгать туклануын оештыру объекты мәйданының бер квадрат метрына 48,1 мең сум;

11) әлеге Законның 2 статьясындагы 1 өлешенең 48 пунктында каралган эшкуарлык эшчәнлеге төре өчен – җәмәгать туклануын оештыруның бер объектына 812,0 мең сум;

12) әлеге Законның 2 статьясындагы 1 өлешенең 65 пунктында каралган эшкуарлык эшчәнлеге төре өчен – транспорт чараларын куеп тору урыны мәйданының бер квадрат метрына 3,0 мең сум.

2. Әлеге Законның 2 статьясындагы 1 өлешенең 1 – 9, 12 – 18, 20 – 31, 34 – 46 (транспорт белән һәм җәяү таратыла торган ваклап сатуга кагылышлы эшкуарлык эшчәнлегеннән тыш), 47 – 82 пунктларында каралган эшкуарлык эшчәнлеге төрләре буенча индивидуаль эшкуар потенциаль алырга мөмкин булган еллык керемнең әлеге статьяның 1 өлешендә билгеләнгән күләменә, муниципаль берәмлекләрнең әлеге Законның 3 статьясында билгеләнгән төркемнәре буенча патентларның гамәлдә булу территориясеннән чыгып, түбәндәге коэффициентлар кулланыла дип билгеләргә:

1) 1,0 – муниципаль берәмлекләрнең 1 нче төркеме өчен;

2) 0,95 – муниципаль берәмлекләрнең 2 нче төркеме өчен;

3) 0,89 – муниципаль берәмлекләрнең 3 нче төркеме өчен;

4) 0,83 – муниципаль берәмлекләрнең 4 нче төркеме өчен;

5) 0,78 – муниципаль берәмлекләрнең 5 нче төркеме өчен.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң бер ай узгач, ләкин салым салуның патент системасын куллануга бәйле рәвештә түләнә торган салым буенча чираттагы салым чорының 1 числосыннан да иртәрәк булмаган вакытта, үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2020 ел, 25 декабрь
№ 90-ТРЗ